ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422645С.Большой Салтан,
ул. Р.Шарафеева, дом 59

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ СОЛТАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422645, Олы Солтан авылы,
Р.Шәрәфи урамы, 59 нчы йорт

Тел.: (84361) 27542, факс: (84361) 27542, e-mail: Bslt.Rs@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.01.2024 Олы Солтан авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законынның 9 маддәснед 3 пункты һәм 12 маддәснед 3 пункты, “Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы һәм “Татарстан Республикасы дәүләт комитеты тариф мәсьәләләре буенча” 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карарларына тәңгәлләштереп, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 һәм 2 кушымтада күрсәтелгәнчә 8 370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм 2024 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварында кабул ителгән “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында”гы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

Олы Солтан авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфиев урамы, 12 йорт, адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сөнгатуллин

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "РЫБНО-СЛОБОДСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН" РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634005346 ОГРН 1061677004400

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Олы солтан авыл
җирлеге Башкарма комитетының
22.01.2024 елның 1 номерлы карарына
кушымта 1

**2024 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5929,46 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү (алып бару) | 841,19 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 1599,55 |
| Җәмгысе: | **8370,20** |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Олы солтан авыл
җирлеге Башкарма комитетының
22.01.2024 елның 1 номерлы карарына
кушымта 2

**2024 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 2963,06 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2963,06 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 836,22 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1607,86 |
| Җәмгысе: | **8370,20** |